СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2022 с. Введенская Слобода №21-116

Введенский Бистәсе авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 апрелендәге 49-214 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең , җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакын билгеләү нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә(2020 елның 29 гыйнварындагы 2-17 номерлы үзгәрешләр белән):

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Советының 2022нче елның 26 октябреннән
21-116 номерлы карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Советының 2022нче елның 26
октябреннән 21-116 номерлы
карарына
12 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе башлыгының акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләренә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов